**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№412**
**30.01.2019**

Гражданнарны аз керемле дип тану һәм аларга социаль наем килешүләре буенча торак бина бирү максатында, аларның керем күләменең һәм мөлкәт бәясенең чик кыйммәтләрен раслау турында

Гражданнарны аз керемле дип тану һәм аларга социаль наем килешүләре буенча муниципаль торак фондындагы торак биналарны бирү максатында, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем килешүләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ санлы Законы һәм шәһәр Уставының 41 маддәсе нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Гражданнарны аз керемле дип тану һәм аларга социаль наем килешүләре буенча торак бина бирү максатында, 2019 елга гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килүче керем күләменең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең түбәндәге чик кыйммәтләрен билгеләргә:

1) гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килүче керемнең чик кыйммәте – 9112 сум 83 тиен;

2) гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең чик кыйммәте:

- ялгыз яшәүче граждан өчен – 831 060 сум;
- ике кешедән торган гаилә өчен – 1 662 120 сум;
- өч кешедән торган гаилә өчен – 2 493 180 сум;
- дүрт кешедән торган гаилә өчен – 3 324 240 сум;
- биш кешедән торган гаилә өчен – 4 155 300 сум;
- алты кешедән торган гаилә өчен – 4 986 360 сум;
- җиде кешедән торган гаилә өчен – 5 817 420 сум;

- сигез кешедән торган гаилә өчен – 6 648 480 сум.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин